**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О присуждении Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова в 2017 году**

Рассмотрев предложения Комитета по присуждению Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова, **постановляю**:

1. Присудить Государственную премию Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова:

1) Бакланову Андрею Владимировичу, кандидату технических наук, начальнику бюро камер сгорания акционерного общества «Казанское моторостроительное производственное объединение» – за выдающийся личный вклад в обеспечение надежной работы камер сгорания газотурбинных установок, применяемых в качестве привода нагнетателя газоперекачивающего агрегата и электрогенератора в газодобывающей отрасли и энергомашиностроении Республики Татарстан и Российской Федерации;

2) Горунову Андрею Игоревичу, кандидату технических наук, доценту кафедры «Лазерные технологии» Казанского национального исследовательского технического университета им. А.Н. Туполева-КАИ – за значительный вклад в развитие методов лазерного аддитивного производства при восстановлении титановых лопаток компрессора авиационного газотурбинного двигателя и штамповой оснастки;

3) Лаптевой Елене Анатольевне, кандидату технических наук, доценту кафедры «Промышленная теплоэнергетика и системы теплоснабжения» Казанского государственного энергетического университета – за значительный вклад в разработку математических моделей и алгоритмов расчета явлений переноса импульса, массы и энергии в аппаратах на предприятиях нефтехимического комплекса.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань,Кремль
16 июня 2017 года
№ УП-506

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2017 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, «Казан моторлар төзү производство берләшмәсе» акционер җәмгыятенең ягулык яндыру камералары бюросы башлыгы Бакланов Андрей Владимировичка – Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең газ чыгару тармагында һәм энергетика машиналары төзелешендә газ кудыру агрегатларында басым җайланмасын хәрәкәткә китергеч сыйфатында файдаланыла торган газ турбиналары җиһазларының ягулык яндыру камералары ышанычлы эшләвен тәэмин итүгә гаять зур шәхси өлеш кертүе өчен;

2) техник фәннәр кандидаты, А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ «Лазер технологияләре» кафедрасы доценты Горунов Андрей Игоревичка – авиация газ турбинасы двигателе компрессорлары һәм штамп җиһазлары титан калакларын рәтләгәндә лазерлы аддитив җитештерү ысулларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, Казан дәүләт энергетика университетының «Сәнәгать җылылык энергетикасы һәм җылылык белән тәэмин итү системалары» кафедрасы доценты Лаптева Елена Анатольевнага – нефть химиясе комплексы предприятиеләрендә аппаратларда импульс, масса һәм энергияне күчерү күренешләрен исәпләүнең математик модельләрен һәм алгоритмнарын эшләүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 16 июнь
№ ПУ-506